Золфәт Хәкимнен пьесасы буенча Фәрит Бикчәнтәев куелышында «Килә ява, килә ява» спектаклен Буа дәвләт драма театры Рузаевка районы Татар Пишләсе тамашачыларына 2017нчы елнын 27 февралендә, Ләмберә районы Пензятка авылында – 28 февральдә, ә шул ук районнын Аксеново авылында беренче мартта күрсәтергә тели.

Әгәр дә сез үзегезнен тормышыгызны берторле диеп уйлыйсыз һәм ул сезне туйдырган икән, сезгә һичюгында безнен комедияне карарга кирәк! Шушы ук коннәрдә кондез яшь тамашачылар очен ике спектакль күрсәтербез. Беренчесе – «Бүре баласы Пожарный» дигән спектакль (3+) нәни тамашачылар очен.

Янгын – ин куркыныч афәтләрнен берсе. Бу хакта бала кечкенәдән үк белергә тиеш. Әлеге спектакль нәкъ менә шул янгын куркынычсызлыгы турында да инде. Урман җәнлекләренә янгын куркынычсызлыгы турында үткәргән дәрес аша балалар шырпы белән уйнау нәрсәгә китерүен, ут һәм янгыннын куркынычлыгы, янгын сүндерүче эшенен жаваплылыгы, авырлыгы турындаәйбәт мәгълүмат алалар. Үен-жыр белән үрелеп барган спектакль бик жинел кабул ителә.

Икенчесе - наркоманиягә каршы «Алсу томан артында» спектаклен яшьүсмерләр очен (12+) күрсәтербез.

Һәр гасырнын – үз проблемасы... Наркомания һәм ташландык балалар – безнен заман чире. «Алсу томан артында» спектакле – урамда әти - әнисез калган ятим балалар язмышы турында... Мондагы вакыйгалар бүгенге кон чынбарлыгын чагылдыра. Әлеге спектакль балаларны да, әти – әниләрне дә, гомумән, киж жәмәгатьчелекне уйланырга мәжбүр итә.

Театр директоры, Татарстаннын атказанган артисты Раил Садриев билгеләп узганча, әлеге спектакль заман чиренә әйләнгән наркоманияне кисәтүгә багышланган.

«Репертуарыбызга мондый эчтәлектәге әсәрләр керү очраклы гына түгел. Без заман белән бергә атлыйбыз, бүгенге жәмгыятьне ни борчый, театрны да шул борчый. Аерым кешеләрне генә түгел, ботен илне хафага салган наркоманияне кисәтү, профилактик юнәлештә эш алып бару, яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә тарту – барыбызнын да уртак бурычы. Ә театр- зур тәрбия мәктәбе ул. Юкка гына, театр яктылыкка, нурга илтә, димиләр бит»,- диде танылган артист.

Буа дәвләт драма театры быел 100 еллык юбилеен билгеләп узарга жыена.

- Бу безнен очен зур тарихи вакыйга,- диде театрнын директоры Раил Садриев. - Буа шәһәрендә беренче спектакль 1917 елнын 4 маенда укытучы Мифтахетдинов

житәкчелегендә куелган. Революциядән сон, шәһәргә артистларнын тулы ижат труппасы килә. Анын составында Камал I, Камал II, Голсем һәм Бари Болгарский, Шакир Саминский, Галия Камская, Ситдик Айдарский, Золәһа Богдановалар була. Ә Буа жирлегендә театр 2002 елнын 16 февралендә яна сулыш алды, дисәк тә һич ялгыш булмас. Мин шул конне, энтузиастларны жыеп, «Горгери кияvләре»н сәхнәләштерә башладым. Шул коннән башлап без 60тан артык спектакль куйдык инде. Татарстаннын ул чактагы Президенты Минтимер Шәймиев Указы белән 2007 елнын 30 мартында Буа дәvләт драма театры оештырылды. Без vзебезнен районда гына тvгел, Татарстан, Россиянен торле тобәкләрендә чыгыш ясыйбыз. Безне хәзер беләләр, таныйлар, һәркайда котеп алалар. Татарстаннын атказанган артистлары Азат Зарипов, Фирзәр Мортазин, шулай ук Илсур Мортазин, Әминә Шәрәфетдинова, әйдәvче артистлар Голзада Камаретдинова, Рима Хәмидуллина, Булат Гәрәев, Ильфир Солтанов, Наилә Имәнгулова, Голназ Гыйззәтуллина, Айгол Сәгдиева, яшь артистлар Ирек Гайнетдинов, Тимур Шиһаповлар - театрыбыз горурлыгы.
Театрнын 100 еллыгы алдыннан Буада 12 марттан 23 кадәр «Идел-Буа-Урал» – яссылыклар диалогы исемле ботенроссия театр фестивале оештырыла. Ул Идел буе һәм Урал халыклары профессиональ драма театрлары фестивале дип кvздә тотылса да, географиясе тагын да кинрәк булачак.
Сезне безнен спектакльләребезгә котеп калабыз.